СОВЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.14, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

Совет мәйданы, 14 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-11-33, факс (84366)3-01-33, 3-14-33. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**Арча район Советы**
**КАРАРЫ**

**« 25 » июль 2024 ел** **№ 295**

**«Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контроле турында нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 12 ноябрендәге 96 номерлы Арча район Советы карарына (28.02.2022 ел, № 124, 25.04.2023 ел, № 213 үзгәрешләр белән) үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында " Федераль законның 2 һәм 3 статьяларына һәм Россия Федерациясенең Торак кодексына үзгәрешләр кертү хакында" 2023 елның 18 мартындагы 71-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Уставына таянып, Арча район Советы карар бирде:

1. 2021 елның 12 ноябрендәге 96 номерлы Арча район Советы карары белән расланган (28.02.2022 ел, № 124, 25.04.2023 ел, № 213 үзгәрешләр белән) Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контроле турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 1.2 пунктын 12 нче пункт белән тулыландырырга һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2. Дәүләт торак күзәтчелеге предметы булып юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр һәм гражданнар тарафыннан торак законнары, энергияне сак тоту һәм энергетик нәтиҗәлелекне арттыру турындагы законнар, муниципаль торак фондыннан тыш, Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турындагы законнар белән билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне үтәү тора:

1) муниципаль торак фондыннан файдалану һәм саклану таләпләре, шул исәптән торак урыннардан файдалану һәм аларны тоту, күпфатирлы йортларда бина хуҗаларының гомуми мөлкәтен куллану һәм карап тоту таләпләре, күпфатирлы йортта торакны торак булмаган бинага һәм торак булмаган бинаны торак йортка күчерү тәртибе, күпфатирлы йортта биналарны үзгәртеп планлаштыру һәм (яки) үзгәртеп коруны гамәлгә ашыру тәртибе;

2) капиталь ремонт фондларын формалаштыруга таләпләр;

3) күпфатирлы йортлар белән идарә итүче, күпфатирлы йортларда гомуми милекне саклау һәм ремонтлау буенча хезмәтләр күрсәтүче һәм (яки) эшләр башкаручы юридик затларны, шәхси эшмәкәрләрне булдыру һәм аларның эшчәнлегенә таләпләр;

4) күпфатирлы йортлардагы һәм торак йортлардагы биналарның хуҗаларына һәм кулланучыларына коммуналь хезмәтләр күрсәтүгә таләпләр;

5) күпфатирлы йортта гомуми милек белән идарә итү, карап тоту һәм ремонтлау буенча хезмәтләр күрсәтү эшләрен тиешле сыйфатсыз һәм (яки) билгеләнгән вакыттан артып киткән өзеклекләр белән башкару очрагында, торак бинаны карап тоткан өчен түләү күләмен үзгәртү кагыйдәләре;

6) күпфатирлы йортта гомуми милекне карап тоту кагыйдәләре һәм торак бинаны карап тоткан өчен түләү күләмен үзгәртү кагыйдәләре;

7) күпфатирлы йортларда һәм торак йортларда милекчеләргә һәм кулланучыларга коммуналь хезмәтләр күрсәтү, туктату һәм чикләү кагыйдәләре;

8) кулланыла торган энергетик ресурсларны исәпкә алу приборлары булган күпфатирлы йортлар һәм торак йортлар биналарының энергетик нәтиҗәлелеге һәм җиһазландырылуга таләпләр;

9) ресурслар белән тәэмин итүче оешмалар, күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшчәнлек алып баручы затлар тарафыннан системада мәгълүмат урнаштыру тәртибенә таләпләр;

10) инвалидлар өчен күпфатирлы йортлардагы биналарны куллануны тәэмин итү таләпләре;

11) социаль файдаланудагы арендаланган йортлардан торак бирү таләпләре;

12) йорт эчендәге һәм (яки) фатир эчендәге газ җиһазларын имин эксплуатацияләүгә һәм техник хезмәт күрсәтүгә таләпләр, шулай ук күпфатирлы йортта гомуми милеккә караган вентиляция һәм төтен каналларын карап тотуга таләпләр.»;

1.2. Нигезләмәнең 1.6 нчы пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.6. Муниципаль торак контроле объектлары:

1) алар кысаларында мәҗбүри таләпләр үтәлергә тиешле, шул исәптән әлеге Нигезләмәнең 1.2 пунктының 1 -12 пунктчаларында күрсәтелгән эшчәнлек алып баручы контрольдә тотылучы затларның эшчәнлеге, гамәлләре (гамәл кылмавы);

2) контрольдә тотылучы затларның эшчәнлеге нәтиҗәләре, шул исәптән әлеге Нигезләмәнең 1.2 пунктындагы 1 - 12 пунктчаларында күрсәтелгән мәҗбүри таләпләр куелган продукция (товарлар), эшләр һәм хезмәтләр;

3) муниципаль торак фондының торак биналары, муниципаль торак фондының торак биналары булган күпфатирлы йортлардагы гомуми милек һәм әлеге Нигезләмәнең 1.2 пунктындагы 1 - 12 пунктларында күрсәтелгән мәҗбүри таләпләр куела торган башка объектлар.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында (arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына йөкләргә.

Арча муниципаль районы башлыгы,
Арча район Советы рәисе И.Г.Нуриев